**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Өркеш авыл җирлеге Башлыгы**

# КАРАРЫ

**10 ноябрь 2023 ел** **№ 49**

**«Кукмара муниципаль районы Өркеш авыл җирлегенең Хасановка авылы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Өркеш авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2023 елның 23 ноябренә 14 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Өркеш авыл җирлегенең Хасановка авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенынын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Хасановка авылы, Урман урамы, 3 нче йорт адресы буенча урнашкан шәхси йортта үткәрергә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар (курсантлар), I төркем инвалидлары, 18 яшькә кадәрге 3 һәм аннан да күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләләр; 18 яшькә кадәрге балаларын тәрбияләүче ялгыз әниләр ,80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге пенсионерлар, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Өркеш авыл җирлегенең Хасановка авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2024 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- урамда тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм Хасановка авылында электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау

- Хасановка авылының Урман урамындагы артезиан коеларын куллануга лицензия алу өчен кагәзләр җыелмасын һәм лаборатория тикшеренүләрен әзерләү буенча чаралар; Хасановка авылының Урман урамындагы артезиан коелары өчен насослар сатып алу һ. б.;

-Хасановка авылында урам яктырту лампаларын, яктырткычларын, махсус җиһазларын һәм башка төр урам яктырту җиһазларын сатып алу, урнаштыру;

-коеларны төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү буенча башка эш төрләре;

-Хасановка авылының Урман урамында янгын гидрантлары һәм тулыландыру материалларын сатып алу һәм урнаштыру, шул исәптән проект-сметасы кагәзләрен һәм технадзорны гамәлгә ашыру;

-һәйкәлләр территорияләрен төзү, ремонтлау һәм төзекләндерү, проект-смета документациясен эшләү;

-Хасановка авылында вак таш һәм асфальт белән капланган юлларны төзү, тоту, төзекләндерү, шул исәптән проект-смета документациясе һәм технадзорны гамәлгә ашыру;

-урам-юл челтәрен тоту, шул исәптән проект-смета документациясе һәм технадзорны гамәлгә ашыру;

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Гражданнар җыенын оештыручы итеп, Өркеш авылы Башкарма комитетын билгеләргә.

4.Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Өркеш авыл җирлеге башлыгы: А.Ш.Әгъләмова